Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423338

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

Ә.Вәлиев урамы, 50нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423338

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2021 ел №6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 04 декабрендә 10.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Ә.Вәлиев урамы буенча 1 йорттан 61 йортка кадәр.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 04 декабрендә 13.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Кооператив урамы буенча 1/1 йорттан 8/2 йортка кадәр, Профсоюз урамы буенча 5 йорттан 23 йортка кадәр.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенның беренче этабын үткәрү вакыты – 2021 елның 04 декабрендә 10.00 сәг тән 11.00 сәг кә кадәр;
- гражданнар җыенның беренче этабын үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе;
- гражданнар җыенның икенче этабын үткәрү вакыты – 2021 елның 04 декабрендә 13.00 сәг тән 14.00 сәг кә кадәр;
- гражданнар җыенның икенче этабын үткәрү урыны – Илбәк авылы, балалар уен мәйданчыгы торриториясе дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 24 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур, 10а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Илбәк торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Илбәк торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2021 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне»,«Сабантуй», «Өлкәннәр көне»,«Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен килешү буенча хезмәт күрсәтү;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне чүп үләннәреннән, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту; килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту буенча хезмәтләр
- Илбәк авылы зираты территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (коймалар алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу һәм контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигезен, коймасын урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина